**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**29 гыйнвар 2025 ел** **№ 118**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советының 2018 елның 4 маендагы 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Авыл җирлекләре башлыкларының социаль гарантияләрен тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы «Даими нигездә дәүләт серенә кертелгән гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» карар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 нче номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карар, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгының 2025 елның 9 гыйнварындагы 1-К номерлы «Хезмәткәрләрне дәүләт серенә кертү турында» боерыг, Красносельский авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы,

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2018 нче елның 4 нче маендагы 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Красносельский авыл җирлеге Советы карарына (2018 елның 24 сентябрендәге 96 нчы номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 4 нче номерлы, 2022 елның 26 октябрендәге 55 нче номерлы, 2022 елның 25 ноябрендәге 60 нчы номерлы, 2023 елның 16 июнендәге 70 нче номерлы, 2024 елның 24 июнендәге 97 нче номерлы,

2024 елның 25 ноябрендәге 112 нче номерлы Совет карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктка абзац өстәргә:

«Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен айлык процент өстәмәсе күләменең һәм авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең вазыйфаи оклады күләменең нисбәте (13 нче кушымта)»;

1.2. Кушымта нигезендә «Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен айлык процент өстәмәсе күләменең һәм авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең вазыйфаи оклады күләменең нисбәте» 13 нче кушымта өстәргә.

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет Рәисе,
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов

13 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красноселський авыл җирлеге Советының 2025 елның 29 гыйнварындагы 118 нче номерлы карары белән расланды

**Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен айлык процент өстәмәсе күләменең һәм авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең вазыйфаи окладı күләменең нисбәте**

| Айлык процент өстәмә | (процентларда) |
|---|---|
| «Аеруча әһәмиятле»серлелек дәрәҗәсенә ия мәгълүматлар белән эшләгәне өчен | 50-75 % |
| «Бөтенләй сер»серлелек дәрәҗәсенә ия булган мәгълүматлар белән эшләгәне өчен | 30-50 % |
| Тикшерү чараларын уздырмыйча гына, рөхсәт рәсмиләштергәндә «яшерен » серлелек дәрәҗәсенә ия мәгълүматлар белән эшләгән өчен, | 10-15 %<br>5-10 % |